Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№14 (107)
7 май 2014 ел





## Җиңү көне белән!!!

Барлык ветераннарны һәм тыл хезмәтчәннәрен Бөек Җиңү көне белән тәбрик итәм.

9 май – һәр Россияле өчен изге бәйрәм, ул күпмилләтле халкыбызның рухи көчен һәм бөеклеген, үз тамырларына һәм тарихына чиксез тугрылыгын ачык чагылдыра. Җиңү безгә зур югалтулар аша килде, бер генә илнең дә үз ирегe һәм бәйсезлеге өчен алай кыйммәт түләгәне юк. Без фронтовикларның батырлыгын мәңге онытмаячакбыз, үлгәннәрне хәтерләячәкбез һәм сугыш турындагы дөреслекне саклап калу өчен тырышачакбыз.

Кулларына корал тотып, дошманга каршы чыккан студентларыбыз, укытучыларыбыз һәм хезмәткәрләребез беркайчан да онытылмаячак. Казан дәүләт университетыннан һәм хәзер КФУ составына керә торган төп югары уку йортларыннан сугышның башлангыч чорында ук студентларның өчтән икесеннән артыгы һәм укытучылар составының яртысы фронтка китә, араларында сугыш кырларында башларын салганнары да аз булмый. Без алар алдында чиксез бурычлы. Тылда калганнар исә Җиңүне киеренке хезмәтләре һәм фәнни иҗатлары белән якынайтканнар.

Бабаларыбыз һәм аталарыбызның сугыш кырларындагы батырлыгы – яшь буын өчен бәхәссез үрнәк. Батырлык, патриотизм һәм фидакарьлек традицияләре бүгенге көндә, катлаулы халыкара вәзгыять шартларында, аеруча мөһим. Нәкъ менә шундый тарихи сынау вакытларында ил гражданнарының рухи байлыгы һәм ныклыгы тикшерелә, шуңа күрә без барлык авырлыкларны җиңәргә һәм тагын да ныгый төшәргә тиеш. Һәм ул шулай булачак та. Университетыбыз коллективы фәнни-мәгариф системасы һәм тулаем ил алдында торган бурычларны тормышка ашыруда үзеннән лаеклы өлеш кертер, бердәмлек, сабырлык, иҗади омтылыш күрсәтер, дип ышанам. Җиңү мирасы – буыннар бәйләнешенең зур мораль ресурсы. Без Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгын лаеклы каршы алачакбыз.

Ветераннарыбызга һәм тыл хезмәтчәннәренә чын күңелемнән нык сәламәтлек, барыбызга да уңышлар һәм тыныч күк йөзе телим.

***Илшат Гафуров,***
*КФУ ректоры*





Липа КДолмашинская фотосы

## Вакыйгалар эзеннән

Укучыларның фәннәр белән кызыксынуын тикшеренү эшчәнлеге аша арттыру максатында, 30 апрель көнне Олы Кайбыч урта мәктәбендә укучыларның **«ПОИСК» II ЗОНА ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ ҮТКӘРЕЛДЕ**. Анда КФУның Психология һәм мәгариф институты укытучылары актив катнашты.

• • • •

**1-2 МАЙ** көннәрендә Бөгелмә шәһәрендә штанга күтәрү буенча ир-ат һәм хатын-кызлар арасында **VII АЧЫК ТУРНИР БУЛДЫ**. Анда Татарстан, Башкортстан, Чувашия, Удмуртия, Ульян һәм Түбән Новгород өлкәсеннән 100дән артык спортчы катнашты. Алабуга институтының «Медведь» хатын-кызлар җыелма командасы гомумкоманда зачетында беренчелекне яулады. Шәхси зачетта исә А.Багаманова (III урын), К.Волкова (I урын), А.Филимонова (I урын), И.Низамбиева (II урын), А.Бәйрәмова (I урын), А.Гарипова (III урын) һәм М.Волков (II урын) призлы урыннарга лаек булды.

• • • •

**3 МАЙ** көнне **КФУ** һәм A.P.Moller – Maersk Group компанияләре төркеменә кергән **«ДАМКО РУС» ҖЧҖ** белән **ХЕЗМӘТТӘШЛЕК** итү турындагы **МЕМОРАНДУМГА КУЛ КУЕЛДЫ**. Килешү 3 елга төзелде. Хезмәттәшлек кысаларында халыкара транспорт белән товар озату, логистика һәм товар белән тәэмин итүне идарә итү өлкәсендә уртак белем бирү программаларын булдыру һәм аларны гамәлгә ашыру каралган.

• • • •

**1-3 МАЙ** көннәрендә Ярославль өлкәсенең Сахареж шәһәрендә мәктәп укучылары арасында уздырылган **«ЧТО? ГДЕ? КОГДА?»** интеллектуаль уенының Россия чемпионатында Н.И.Лобачевский ис. **ЛИЦЕЙ УКУЧЫЛАРЫ ҖИҢҮ ЯУЛАДЫ**. Анда Казанны ике команда: «Случайная статья» (7-9 сыйныфлар) һәм «Кажется кто-то олень» (10-11 сыйныфлар) тәкъдир итте. Җиңү яулаган «Кажется кто-то олень» командасында лицей укучылары Г.Чепик, Л.Кузнецов, В.Анисимов һәм Д.Галиәкбәров бар иде. Аларны тәбрик итәбез!

• • • •

**3 МАЙДА** Физика институтында **«ГЕЛИЙ ӨСЛЕГЕНДӘ 2D-ЭЛЕКТРОННАР ҺӘМ КВАНТЛЫ МӘГЪЛҮМАТ»** Халыкара конференциясе эшли башлады. Әлеге чарада катнашу өчен, Украина, АКШ, Бөекбритания, Австрия, Германия, Франция, Япония, Тайвань һәм Россия галимнәре бергә җелды. Алар биш көн буе үзләрен борчыган сорауларга җавап эзләде һәм тәҗрибә уртаклашты.

• • • •

**5 МАЙДА** Филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр институтында «Әдәбият һәм сәнгатьтә документальлек һәм сәнгатьлелекнең синтезы» **V ХАЛЫКАРА КОНФЕРЕНЦИЯСЕ ҮЗ ЭШЧӘНЛЕГЕН БАШЛАП ҖИБӘРД**е. Бу конференция – КФУ базасында ике елга бер уздырыла торган чара. Катнашучылар үзләренең эшләрен «Тарихның әдәби интерпритациясе», «Мемуар-биографик прозаның жанрлы үзенчәлеге», «Матур әдәбиятта документ», «Драма, уен һәм сынлы сәнгать төрләрендә документализм» секцияләрендә тәкъдим иттеләр.

• • • •

Казанда узган **II ХАЛЫКАРА ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ОЛИМПИАДАСЫ** көннәрендә Филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр институтында Кырым һәм Төркиядән килгән галимәләр кунакта булды. Очрашу вакытында сүз, нигездә, укыту программалары һәм юнәлешләре, тел өйрәнү курслары, фәнни проектлар, уртак конференцияләр, укытучылар һәм студентлар алмашу хакында барды. Кунаклар КФУның эшчәнлеге белән һәрдаим кызыксынып торуларын, университет уңышларына шатлануларын белдерде.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

## 9 Май – Җиңү көне

Бөек Ватан сугышы башлангач, фронттагы сугашчыларны туган телләрендә фронт һәм тыл яңалыклары белән таныштырып бару өчен, татарча фронт газетасы оештыру зарурияте туа. Шуны гамәлгә ашыру максатыннан, ү1942 елдан милли телләрдә хәрби газеталар чыгарыла башлый. Фронт газеталарының тиражы аз булмаган: 5 солдатка 1 газета туры килгән. Бөек Ватан сугышы елларында төрле фронтларда 16 исемдә татар газеталары чыккан. Татар язучылары, журналистлары сугышчылар белән бер сафта атакага бара; дошман уты астында окоптан-окопка йөреп, фашистларга каршы аяусыз сугышкан батыр солдатлар һәм офицерлар белән турыдан-туры танышып, татар халкының баһадир уллары турында хәбәрләр җыя. Шуның өчен без, яшь буын, Җиңү көне җиткән саен, фронтовик әдипләребезнең исемнәрен зур хөрмәт белән искә алырга, аларның изге, бөек эшләре белән хаклы рәвештә горурланырга тиеш.

# Фронтта да туган тел сагында

1942 елның 10 июлендә Төньяк-Көнбатыш фронтта беренче булып татар телендә **«Ватан өчен»** фронт газетасы чыга башлый. Ул 1944 елның апреленә кадәр дөнья күрә. Газетаның татар редколлегиясе составында мөхәррир урынбасары булып журналист капитан Г.Гыйльманов, хәрби корреспондентлар булып язучы Х.Госман, яшь шагыйрь Ш.Мөдәррис, журналист А.Әхмәдиев, Н.Яһудин (сугыш алдыннан Арча ягында укытучы) эшлиләр. Бу редакциягә Казаннан партиянең Өлкә Комитеты командировкасы белән танылган язучыларыбыз Гомәр Разин (Гомәр Бәшировның тәхәллүсе) һәм М.Әмир киләләр, ике айга якын биредә хезмәт итәләр.




**«Алга, дошман өстенә»** – 1942 елның ноябреннән Калинин фронтында татар телендә чыккан икенче фронт газетасы. Бу газета Мәскәү яныннан Балтыйк диңгезенә кадәр 1295 километрга сузылган зур, авыр һәм данлы тарихи юл уза. Татар редколлегиясе составында мөхәррир урынбасары журналист М.Гыймадиев, хәрби корреспондентлар булып язучылар Ш.Маннур, А.Шамов, А.Әхмәт, журналист К.Ахмәров, корректор Ф.Басыйров эшли. «Алга, дошман өстенә» газетасы битләрендә үткен телле, юморга бай кечкенә хикәяләр, фельетоннар, кызыклы хәлләр, парчалар, гармун көенә җырлана торган такмаклар, сатирик шигырьләр, Хуҗа Насретдин турындагы тапкыр мәзәкләр күп урын алган.

1942 елның 19 декабрендә Воронеж фронтында **«Ватан намусы өчен»** дип аталган газета чыга башлый. 1943 елда Воронеж фронты таркатылгач, газета, исемен үзгәртмичә, Беренче Украина фронты карамагына күчерелә һәм 1946 елның 25 маена кадәр чыгуын дәвам итә. Татар телендә аның барлыгы 377саны дөнья күрә. Газетаның мөхәррир урынбасары булып шагыйрь, капитан Әхмәт Ерикәй, 1943 елның 1 июленнән драматург, капитан Р.Ишморат эшли. Г.Хуҗи, Ә.Юныс, М.Садри, язучы Г.Бакиров, журналист Ә.Ямангулов, З.Шаһиморатов, Г.Шәрипов эшлиләр. Язучы Г.Иделле һәм журналистка Ф.Галиева 1944 елның нояберennән 1945 елның мартына кадәр редакциядә иҗат командировкасында булалар.

**«Сталин байрагы»** газетасы 1943 елның гыйнварында Көньяк фронтта, данлы Сталинград янында оештырыла һәм март аеннан чыга башлый. 1943 елның 20 октябрендә Көньяк фронт таркалгач, бу газета да, исемен үзгәртмичә, Дүртенче Украина фронты карамагына күчерелә һәм Кырым операциясе тәмам булганчы – 1944 елның июненә кадәр чыга. Газетаның редактор урынбасары булып журналист Г.Клиблеев, хәрби корреспондентлар булып язучы И.Гази, журналист З.Әхмәров һәм корректор К.Хисмәтуллин эшли. 1943 елның 18 гыйнварында язучы Ф.Хөсни, партиянең Татарстан Өлкә Комитеты карары белән, Көньяк фронтка ике айлык командировкага җибәрелә.

**«Фронт правдасы»** газетасы 1943 елның гыйнварында Волхов фронтында чыга башлый һәм бу фронтта сугыш операцияләре тәмам булганчы – 1944 елның февраленә кадәр чыгып килә. Редактор урынбасары булып журналист Г.Хәбиб эшли. Хәрби корреспондент булып шагыйрь Ә.Фәйзи хезмәт итә. Шул ук фронтта герой-шагыйрь Муса Җәлил актив эшчәнлек күрсәткән «Отвага» газетасы да чыга, анда Җәлилнең рус һәм татар телләрендә шигырьләре басыла.

**«Ватан өчен сугышка»** газетасы Карелия фронтында 1943 елның гыйнварында чыга башлый. 1943 елның июненнән редактор урынбасары булып журналист Б.Корбанов, җаваплы секретарь булып язучы Г.Әпсәләмов, хәрби корреспондент булып журналист М.Сабельев эшли.1944 елның февралендә ике фронт – Карелия һәм Волхов фронтлары идарәләре бергә кушыла, чөнки Волхов фронты шулай ук яшәүдән туктый. Редакциядә дә үзгәрешләр барлыкка килә. «Ватан өчен сугышка» газетасының соңгы саны 1944 елның 12 ноябрендә дөнья күрә. Газетаның барлыгы 89 саны чыгып кала. Г.Әпсәләмовның газета битләрендә бик күп очерклары басыла.

**«Ватанны саклауда»** газетасы Ленинград фронтында 1943 елның башыннан 1946 елның июненә кадәр чыгып килә. Газетаның редактор урынбасары – журналист, капитан З.Исхаков, хәрби корреспондентлар булып И.Аргынбаев, И.Сәйфетдинов. К.Юллашев эшли. Бу газета эшендә Ленинград фронты частьларының берсендә хезмәт итүче яшь шагыйрь М.Хөсәен актив катнаша. Аның патриотик эчтәлекле күп кенә шигырьләре һәм үткен очерклары шушы газетада урын ала. Газета битләрендә Г.Насрыйның «Минометчы Нуретдинов» (1945, 14 март) һәм Г.Кутуйның «Куркусыз разведчик» (1945, 22 март) исемле очерклары да дөнья күрә.

**«Фронт хакыйкате»** газетасы Икенче Белорусия фронтында 1944 елның маеннан 1945 елның июненә кадәр чыга. Газетаның мөхәррир урынбасары журналист Г.Гыйльманов, хәрби корреспондентлар булып А. Әхмәров, шагыйрьләр Ш.Мөдәррис һәм Г.Насрый, А.Салеев эшли. Фронт частьларының берсендә хезмәт иткән А.Расих та газетага бик актив яза. Газета редакциясе икенче Белоруссия фронты сугышчыларыннан татар халкына җавап хаты оештыра. Ул шигъри өслүбтә язылган, аның авторы – шагыйрь Ш.Мөдәррис. Ул Җиңү көнен Берлинда каршылый. Рейхстаг диварына «Татар солдаты, шагыйрь Шәрәф Мөдәррис» дип култамгасын язып калдыра.

**«Кызыл армия»** газетасы Беренче Белоруссия фронтында 1944 елның ноябреннән 1946 елның февраленә кадәр чыга. Газетаның мөхәррир урынбасары журналист Я.Ярмәкиев, хәрби корреспондентлар булып язучылар И.Гази, Г.Кутуй, Г.Галиев, журналистлар З.Әхмәров, К.Хисмәтуллин эшли. Бу газета битләрендә Г.Кутуйның «Без – сталинградчылар» (1945, 4 февраль) нәсере һәм «Хәнҗәр» (1945, 1 май) хикәясе дөнья күрә. Шушы ук чорда әдипнең атаклы «Сагыну» нәсере иҗат ителә.

**«Сталин сугышчысы»** газетасы Беренче Ерак Көнчыгыш фронтында 1945 елның маеннан 1945 елның ноябренә кадәр чыга. Мөхәррир урынбасары, журналист Г.Хәбиб, хәрби корреспондентлар булып язучы Г.Әпсәләмов, шагыйрь Г.Габидуллин, журналист К.Иманкулов эшлиләр.Бу газета битләрендә Г.Әпсәләмовның «Диңгезче» (1945, 1 сентябрь), «Якташым» (1945. 8 сентябрь) очерклары һәм «Мәхәббәт һәм нәфрәт шагыйре» (1945, 3 октябрь; Фатих Кәрим турында) мәкаләсе басылып чыга.

**«Совет сугышчысы»** газетасы Өченче Украина фронтында 1943 елның маеннан 1946 елның февраленә кадәр чыга. Газетаның мөхәррир урынбасары язучы Мәхмүд Максуд, хәрби корреспондентлар булып М.Кәрим, Г.Әхмәтшин, А.Әсәдуллин һәм В.Вәлиев эшлиләр. Бу газета редакциясенә 1943 елның 10 октябрендә иҗат командировкасына язучы Х.Хәйри килә. «Мин сау-сәламәт килеп җитеп, эшкә керештем... Газета начар түгел. Эше дә шактый. Аз гына срокка килгән кеше, мин дә кайбер эшләрне башкарырмын дип торам», – дип яза Х. Хәйри Хәмит Ярмигә 1943 елның 13 октябрендә. Х.Хәйринең газета битләрендә «Сугышчан әдәбият» (1943, 20 октябрь), «Халык батырларына дан» (1943, 29 ноябрь) исемле мәкаләләре басыла. М.Максудиның «Патриот-шагыйрь» (1943, 3 декабрь; Г.Тукай иҗаты турында) зур мәкаләсе дөнья күрә.

• Сәяхәттән кайткач

# Чәй, карабодай... Тукай???

**Алия РИЗВАНОВА,** Экология
һәм география институты

26 апрель безнең өчен гадәти көн кебек үк башланып китте: торасы килмәү, иртәнге кәефсезлек, бөтенесенә кул селтәп, кире җылы юрган астына кереп яту теләге... Өстәвенә, төнлә яуган кар бу халәтне тагын да көчәйтеп җибәрде. Шулай да бу көнне ниндидер гадәти булмаган дулкынландыргыч хис бар иде. Нәкъ шул хис безгә караваттан аерылып китәргә ярдәм иткәндер дә.



Ниндии хис, ни турында сөйли соң бу, дип баш ватасызмы? Бу көнне КФУның Экология һәм география институты географик һәм экологик белем бирү бүлегенең «Семь румбов» турклубы вәкилләре белән Арча районы Кушлавыч авылына өйрәну походына юл тоттык. Җылырак һәм кояшлырак көнне барып булмый идеме әллә, дип уйлаучылар да табылыр. Юк, булмый иде, чөнки әлеге 2 көнлек күмәк походыбыз Россия Федерациясендә мәдәният елы кысаларында һәм татар халкының бөек шагыйре Г.Тукайның туган көненә багышланган иде.

Походны ЭһГИның географик һәм экологик белем бирү теориясе һәм методикасы кафедрасы ассистенты, «Семь румбов» түгәрәге җитәкчесе Р.Фәрхуллин һәм халыкара класслы гид-проводник, туризм буенча Россиянең спорт мастеры, Россиянең атказанган сәяхәтчесе, Остапец-Свешков ис. туризм һәм төбәкне өйрәнү халыкара академиясе академигы, ТРның атказанган физик тәрбия хезмәткәре И.Җамалетдинов оештырды.

Шулай итеп, шимбәнең салкынча иртәсендә, аркаларыбызга бик үк җиңел булмаган рюкзаклар асып, тимерюлвокзалынаюлтоттык. Анда инде «румб»лы иптәшләребез җыелып беткән иде. Электричкага утырып, мажараларга таба юл тоттык. Җәяүле сәяхәтебез Казаннан 45 км ераклыкта урнашкан Камаево станциясеннән башланып китте. Камаево халык телендә Иске Казан дип йөртелә, һәм, бәхәссез археологик дәлилләр булмауга да карамастан, күпләр Казан элек шушы урында булган дип уйлый.

Елга, сөзәклек, ерым кебек каршылыкларны җиңәҗиңә хәйран гына атларга туры килде. Алга баруга комачаулый торган көчле җил һәм салкын, битне тырный торган кар, пычрак һәм җепшек, юешләнгән аяклар, егылулар – болар безне беренче көннән, беренче минуттан үк эзәрлекләп бардылар. Кәкрәеп беткән, менә-менә җимереләм дип торган кечкенә генә күпер аркылы чыгуымны һаман да курку хисе белән искә алам. Шулай да, безнең күңелләр шат, кәефләр күтәренке иде. Юлны һәм үзебезне көлүебез, шаяруларыбыз, мәзәкләребез, җырларыбыз, биюләребез җиңеләйтеп торды. Арабызда Африкадан ике чит ил студенты да булганлыктан (Есуф һәм Огастаин), инглиз теле күнекмәләребезне дә ныгыттык. Юлыбызда изге булып саналаган тау һәм күпсанлы чишмәләр очрады. Шулай ук Иске Казан дәүләт тарихи-мәдәни һәм табигый музей-тыюлыгы белән танышу бәхетенә дә ирештек.



Кичкә таба, йоклар урын билгеләнгәч һәм тамак ялгап алу өчен учак яндырып җибәргәч, бераз җиңел сулап куйдык. Учак тирәли кич утыруыбыз аеруча якты тәэсирләр калдырды. Күңелле аралашу, Г.Тукай шигырьләре һәм җырлары, уеннар, ихлас көлүләр, айлы күк йөзе, тавыш биреп утыручы күршеләребез – кондызлар, учакта әзерләнгән тәнне һәм җанны туңудан коткаручы чәй... Бик нык арыганлыкка да карамастан, берәүнең дә бу мохитне калдырып йокларга китәсе килмәде.

Һава торышы безне кызганды булса кирәк, икенче көнне җылытты. Салмак кына җил һәм кояшның җылы нурлары безне Г.Тукайның туган җиренә кадәр озата барды. Анда Тукаевлар гаиләсенең музей-йорты белән таныштык, соңрак Бөек шагыйрьнең әтисе күмелгән зиратка юл тоттык.

Өйгә кайту юлы җиңелрәк кебек тоелды: кояш та җылырак яктыртты, күңелләр дә күтәренке булды. Шундый пычранган, арыган, янган-көйгән, әмма бәхетле һәм үз-үзебездән канәгать булу хисләре белән перронда Казанга алып кайта торган электричканы көттек. Менә шулай итеп, онытылмаслык һәм якты тәэсирләр калдырган җәяүле походыбыз тәмамланды да. Экскурсия кыска булса да, аннан калган матур хатирәләр, һичшиксез, озын гомерле булачак!

***Есуф Сирадж:*** *«Мин Г.Тукайның туган җирендә булган һәм аның йортында Коръәнукыган Эфиопиядән килгән беренче кешедер. Татарстан буенча җәяүле походка чыгуым да тәүге тапкыр булды. Тушенка белән пешерелгән карабодай боткасы һәм апельсинлы чәй тәмен мәңге онытмаячакмын. Мондый искиткеч маҗара өчен оештыручыларга зур рәхмәт!»*

***Огастаин Бойма:*** *«Беренче көнне бик туңганлыктан, табигать кочагында үткәргән төн гомерлеккә истә калачак. Шуны да әйтәсем килә: безнең белән барган кызлар кызык, шаян, акыллы, матур һәм көчле рухлы иделәр. Аларга карап, мин дә көчле буларга тырыштым. Бу походта юешләнгән аяк киемендә берьюлы яңгыр, боз, көчле җилнең тәэсирен татып карадым. Шулай ук татар халкының мәдәнияте һәм көнкүреше белән таныштым».*

• Милли мирас



# Тибрәтмәкче булсаң халык күңелләрен...

**Лилия ЯКУПОВА,** Филология һәм
мәдәниятара багланышлар институты

Ел да шаулап-гөрләп халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайның туган көне уза. 29 апрель көнне КФУ ның 8 нче номерлы студентлар тулай торагында да Г.Тукайның 127 еллыгына багышланган күркәм кичә үтте.



Әлеге дата белән бәйле рәвештә төрле чаралар, акцияләр елдан-ел арта бара, яшьләрнең бу чараларга күпләп кушылулары тагын да сөендерә. Бу кичтә дә бирегә шигъри җанлы, сәнгать сөюче, җыр-моңга гашыйкстудентларҗыелган иде. Кунаклар – Миңгол Галиев, аның шәкертләре һәм иҗатташ дуслары – кичәгә үзенчәлекле рух өстәделәр. Г.Тукай исемендәге ТФМББ, Л.Н.Толстой исемендәге РЧФБ һәм юридик факультет, шул исәптән, чит ил студентлары, Г.Тукайның иҗатын хәтерләрендә яңартты, аңа багышлап язылган шигырьләр белән дә танышты, Миңгол Галиев башкаруында җырларын тыңлады. Чын мәгънәсендә милли җанлы очрашу булды. Иң кызыгы шунда: кичәдән алган тәэсирләр шулкадәр көчле иде ки, студентлар тиз генә таралышырга ашыкмады, татар, рус милли көйләренә кушылып, рәхәтләнеп биеде, күңел ачты.

Кичә буласын ишеткәч, гадәти генә булыр дип, әллә ни зур яңалык көтмәгән идек. Әмма нәкъ шул гадилек күңелгә үтеп керә алды, оештыручыларның (8 нче номерлы студентлар тулай торагының педагог-тәрбиячесе Гөлчәчәк Муллахмәтова, комендант Резеда Нәбиуллина) һәм катнашучыларның күңел җылысына төреп бирелгән шигырьләр, җырлар тамашачыны битараф калдырмады. Куллар үзеннән үзе алкышлады, ихтыярсыздан артистларга кушылып җырланды. Бик күркәм, күңелгә үтеп кererлек ихлас узды бу кичә. Татарларга, гомумән, борынгыдан ук ихласлык, тыйнаклык хас булган. Әйтәсем килә, яңалык артыннан куып, гади генә булып тоелган, ләкин күңелгә ятышлы традицияләребезне онытмасак иде! Сагындыра икән алар, сагындыра!..

• Туган тел сагында

# Бөтен дөнья татарча сөйләшә

Татар телен белгән кешенең кулында бөтен ишекләргә туры килерлек ачкыч бар икән. Татар теле һәм әдәбиятыннан II Халыкара олимпиада – моның дәлиле. 27-30 апрельләрдә Казан шәһәренең үзәге, чын мәгънәсендә, кайнап торды, чөнки бөтендөнья буенча татар яшьләренең каймагы шунда җыелган иде.



**Руфинә ГАБДРАХМАНОВА,**
Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

Бераз гына статистика. Әлеге олимпиада, әле икенче тапкыр гына уздырылса да, яшьләр арасында инде популярлашып та өлгергән. Халыкара олимпиаданың беренче туры читтән торып, онлайн-тест язу режимында узган иде. 9-25нче декабрьдә булган дистанцион турда Россия, Таҗикстан, Казакъстан, Үзбәкстан, Төркия, Бельгия, Эстония, Кытай, Япония, БГӘ, Австралия һәм Канада илләреннән якынча 5 мең укучы һәм студент катнашкан. Иң яхшы нәтиҗәләр күрсәткән 300 катнашучы, белемнәрен сынау өчен, Казанга җыелды.

Катнашучылар урнашкан шәһәр үзәгендәге «Биләр Палас» кунакханәсе – татар яшьләре йорты иде бу көннәрдә. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы бу бәйгене оештыруга бик күп көч куйды. Программа бик уңышлы һәм кызыклы эшләнгән иде: Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында «Гөргөри кияүләре»н дә карадык, Казанның тарихи урыннары буенча экскурсиядә дә булдык, «Мин татарча сөйләшәм» акциясендә дә күңел ачтык, Су спорт төрләре сараенда синхрон йөзү буенча Россия чемпионатының ялгыз чыгышларын да күзәттек, «Әкият» театрында караган «Нигез ташлары» спектакле күңелдә татарлык хисен уятып җибәрүнең кульминациясе булгандыр.



Олимпиада булгач, ярыш-бәйге турында онытмаска кирәк. Интеллектуаль һәм иҗади турларда (җыр, бию, нәфис сүз) катнашучылар төрле яктан ачылдылар, шуның белән татар телен белү дәрәҗәләрен һәманаңа булган мөнәсәбәтен күрсәттеләр. Олимпиаданың «бәйге» өлешен үткәрүдә безнең alma mater Казан (Идел буе) федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты хезмәткәрләре тырышты. Һәр катнашучының чыгышын аерым игътибар белән карап бәяләп бардылар.

Олимпиада берләштерә. Бу көннәрдә күпме дуслар таптык, туганлашып беттек, дисәк тә ялгыш булмас. Казакъстанның Астана шәһәреннән килгән Мәрьям Галләмова үз хисләре белән уртаклашты: «Астанада Татар җәмгыятенә йөрим, татарча аралашу мөмкинлеге бары тик шунда һәм гаиләдә. Казанга беренче тапкыр гына килсәм дә, ул мине әсир итте. Иң матур шәһәр Казан икән. Хәтта китәсе килми». Аралашуда татар теле беренче урында иде. Чит илләрдән килгән татарлар белән аралашасың килсә, син йә инглиз телен, йә татар телен белергә тиешсең.

Татар теле һәм әдәбиятыннан II Халыкара олимпиада күңелләрдә сүнмәс йолдыз кабызды, милләтем белән горурлану хисе уятты. Татар халкы төрле тарафларга сибелгән булса да, ул бердәмлеген югалтмаган икән. Мондый төр чараларның булуы татар яшьләре өчен бик мөһим. Татар теле югала барган дәвердә, чит илләрдән җыелган яшьләрнең татарча иркен аралашуын күреп, республикабыз яшьләре фикер үзгәреше кичерсен иде. Татарлык! Олимпиадада катнашкан һәркем күңелендә шушы хистән дә зуррак кичереш юктыр.

***P.S.*** «Биләр Палас» диварлары татар яшьләренең «Мин татарча сөйләшәм» акциясендә отып алган шигарен озакка истә калдырыр кебек: «Мин татарча сөйләшәм – киләчәкне үзгәртәм!».

• Киңәш-табыш

## Файдалы да, чамалы да!

Яз җитүгә, күпләр каен суы җыярга ашыга. Ләкин без аның файдасы, зыяны турында уйлап торабыз микән? Аннары, каен безгә рәнҗеп калмасмы?

Медицина тикшеренүләре күрсәтүенчә, 3 атна буена, көнгә бер тапкыр булса да, бер стакан каен суы эчү язгы хәлсезлек, авитаминоз, арыганлык һәм депрессиягә каршы сизелерлек ярдәм итә. Ә иң әйбәте: аны көнгә 3 тапкыр ашарга ярты сәгать кала куллану. Каен суы, каен серкәсенә аллергиясе булган кешеләргә киңәш ителми.

Фитотерапия күзлегеннән караганда, каен суы табигый продуктлар арасында матдәләр алмашуын яхшыртучы иң яхшы чара булып тора. Гади судан аермасы бик зур булмаса да, каен суы ашказаны эшчәнлегенә уңай тәэсир итә, чөнки ул бик яхшы һәм тиз эчү үзенчәлегенә ия.

Шулай ук каен суы организм өчен кирәкле шикәрләр, органик кислоталар, ферментлар, кальций, магний, тимер тозлары, микроэлементларга бай. Аны авитаминоз, кан авырулары, буыннар, тире авырулары, шулай ук ангина, бронхит, үпкә ялкынсынуы (пневмония) һәм башка тын юллары авырулары вакытында кулланырга киңәш итәләр. Шулай ук ашказаны җәрәхәте, бавыр, уникеилле эчәк, үт куыгы, радикулит, ревматизм, артрит, туберкулез, баш авыртулары һәм венерик чирләрдән дә файдасы бар. Тире авырулары вакытында да каен суы эчү яхшы нәтиҗә бирә. Организмны зарарлы матдәләрдән чистарта. Әмма бөерләрендә таш булган кешеләргә аның белән артык мавыкмаска киңәш ителә.

Шуны да истә тотыгыз: каен суы файдалы дип, язын шифалы суны күп җыярга ярамый. Урманга баргач, калын кәүсәле зур каеннарны сайлагыз. Аның кәүсәсендә тирән булмаган кисем ясап яки ике-өч сантиметр тирәнлектә тишек уеп, аңа көпшә куярга кирәк. Суны җыйганнан соң, аны ничек бар, шулай калдырып китмәгез. Кәүсәдәге тишекне балавыз яки балчык белән сылагыз. Каен сезгә рәнҗеп калырлык булмасын!



• Аталар сүзе - акылның үзе

# Дан сезгә дан, игенчеләр!



**Динара МИННЕКАЕВА**

Бай тарихы, матур традицияләре, милли йолалары булган милләт син, халкым! Горурланып, мин – татар кызы, дип йөрим! Тырыш халкым, калганнарга үрнәк халкым белән горурланам. Аллага шөкер, шушы болганчык чорда да, әшәкелек чәчәк аткан заманда да изге күңелле кешеләр, телгә, мәдәнияткә, йолаларыбызга, традицияләргә зур хөрмәт белән карый торган, аны яшь буынга тапшырып калдырырга теләүчеләр бар. Андый шәхесләр белән танышу, аралашу җанга рәхәтлек бирә. Үзең өчен, булачак балаларың, оныкларыңның киләчәге өчен иркен сулап куясың.

Азнакай районы башка районнардан миллилеге, халыкчанлыгы, эшчән булуы, традиция-йолаларга сакчыл карашы белән аерылып тора. Бер кайтуыбызда Чуар-Абдул авылы халкының язгы чәчүгә әзерләнеп йөрү чорына туры килдек. Биредә бу көн гадәти генә башланмый икән. Борынгыдан килә торган йомырка тәгәрәтү йоласын үз күзләрем белән күрү бәхетенә ирештем.

«Кеше элек-электән үк Җиргә инанган. Хәзер генә аңа кадер-хөрмәт бетеп бара. Күпме басулар буш ята. Ә бездә шундый традицияләрнең саклануы, колхозыбызның чәчәк атуы күңелне сөендерә», – ди бабайлар, дулкынлануларын яшерә алмыйча. Чәчүгә чыгар алдыннан, авылның мөхтәрәм бабайлары басуга чыгып азан, тәкъбир әйтәләр. Аллаһы Тәгаләдән басуда эшләүчеләргә, җитәкчеләргә исәнлек-саулык сорыйлар, армый-талмый эшләсеннәр, вакытында яңгырлары явып, уңышны вакытында җыеп алырга язсын, дип телиләр. Аннары «Шушы йомыркалар кебек тәгәрәшеп үсегез», – дип буразналар арасына йомырка тәгәрәтәләр. Бу җирнең уңдырышлы булуын Җир Анасы һәм Җир Атасыннан сорау буларак аңлатыла икән. Ә йомырка символикасына мөрәҗәгать итсәк, аның үрчем белән бәйле булуын күрәбез, чөнки дөнья яралуы да Дөнья йомыркасы образы белән бәйле.

Әлбәттә, мондый ышанулар юкка гына түгелдер. Берничә ел элек булган корылыкны барыбыз да яхшы хәтерли. Шул авыр елда да «Тукай» хуҗалыгы яхшы уңыш җыеп алып, кышка азыкны мулдан әзерлиләр, икенче елны үз орлыкларын чәчәләр. Уңышның сере йолаларны зурлауда, авыл халкы белән бердәм булуда икән. Тырыша халкым... Көнне-төнне белмичә, бертуктаусыз эшли дә эшли. «Тукай» авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре кебек тырыш халкым, Габделәхәт абый Рәфыйков кебек җитәкчеләр булганда, шәһәрләр иписез калмас. Әнә бит, алар ял да дими, бәйрәм дә дими, эшли, инде Җиңү көнен язгы чәчүне тәмамлап каршы ала.

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш.,
Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.